**Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Әмзә авыл җирлеге Яңа Әмзә авылы торак пунктында гражданнар җыены КАРАРЫ**

«10» апрель 2024 ел № 2

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Әмзә авыл җирлеге Яңа Әмзә авылы торак пункты гражданнары җыены

КАРАР ИТТЕ:

Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Әмзә авыл җирлегенең Яңа Әмзә торак пунктында гражданнар Җыенының 24.11.2023 ел, №10 карарына үзгәрешләр кертергә, аны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

1. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Әмзә авыл җирлеге Яңа Әмзә авылында яшәүче, 1 гр инвалидтан тыш, балачак инвалидларыннан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол калган хатыннарыннан, көндезге уку формасы буенча укучы студентлардан тыш, балигъ булган һәр кешедән 2024 елда 1000 сум күләмендә үзара салым кертергә һәм җыелган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:

1) Җир асты суларының табигый чыгу урыннарын төзекләндерү (Яңа Әмзә авылындагы чишмә);

2) Яңа Әмзә авылы чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, тоту (СШР-2.0 П тагылмалы җиһазларны сатып алу);

3) тышкы яктырту урам челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләре һәм электр энергиясен тапшыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны ремонтлау;

4) Яңа Әмзә авылы чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юллары составына кермәгән җәяүлеләр

күперләрен һәм юл үткәргечләрен, җәяүлеләр өчен җир өсте юлларын ремонтлау.

Халык җыенында рәислек итүче Ә.Ф.Сафиуллина

Әмзә авыл җирлеге башлыгы Ә.Ф.Сафиуллина